РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУВАШСКО-КИЩАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ КИШТӘГЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«17» февраль 2023 № 5

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 4 апрелендәге 10 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Регламентның 3.3.2.1. пунктындагы 11 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Запросны формат-логик тикшерү гариза бирүченең электрон формадагы һәр кырын тутыру процессында орган (оешма) тарафыннан билгеләнә торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм порталы тарафыннан запросның электрон формасы кыры дөрес тутырылмаса, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны электрон рәвештә сорауның мәгълүмати хәбәре аша бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. 5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

ТР Буа муниципаль районы
Чуаш Киштәге авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.А. Павлов